СОВЕТ ЮРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮРТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлеге составына кергән Юртау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

17 ноябрь, 2019 ел №1

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ нең 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы №45-ЗРТ Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар түбәндәге мәсьәлә буенча җыен беркетмәсе төзелде:

"2020 елда Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең Юртау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (*көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш*) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?"

-юлларга вак таш түшәү (торбалар, вак таш сатып алу, җәю, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

- Юртау бистәсендә чишмәне төзекләндерү (Су җыю һәм агу өчен сыешлык һәм торбалар сатып алу, урнаштыру һәм буяу. Грунт эшкәртү. Мәйданчыкка һәм чишмәгә илтүче тротуарларга җәю өчен вак таш һәм ком сатып алу һәм җәю. Әвеслек һәм култыксалар төзелеше өчен материаллар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 294 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар җыенында катнашучылар саны 167 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 167 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;

“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең Юртау торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – гамәлдә дип танырга.

“2020 елда Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең Юртау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән (*көндезге формада укучы студентлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, 1 һәм 2 нче төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш*) 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” соравы буенча карарны танырга һәм алынган чараларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә”:

-юлларга вак таш түшәү (торбалар, вак таш сатып алу, җәю, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

- Юртау бистәсендә чишмәне төзекләндерү (Су җыю һәм агу өчен сыешлык һәм торбалар сатып алу, урнаштыру һәм буяу. Грунт эшкәртү. Мәйданчыкка һәм чишмәгә илтүче тротуараларга җәю өчен вак таш һәм ком сатып алу һәм җәю. Әвеслек һәм култыксалар төзелеше өчен материаллар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Юртау авыл җирлеге Советының ТР, Минзәлә муниципаль районы, Юртау бистәсе, Юл ур., 1А йорты адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында: http://menzelinsk.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы һәм http://pravo.tatarstan Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматенең рәсми порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гамәлдәге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенә җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче ____________________ И.Ю.Кадыров.
муниципаль берәмлек Башлыгы ____________________ И.Ю.Кадыров.
Совет рәисе